ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЕНАБЕРДИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ТОЙМА АВЫЛЫНДА
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

КАРАР КАРАР

2022 елның 19 декабре №6

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Тойма авылында 2023 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Енабердино авыл җирлеге Тойма авылы җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. Менделеевск муниципаль районы Енабердино авыл җирлегенең Тойма авылында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә, белем алуның көндезге формасы студентларыннан, вакытлы хәрби хезмәт хезмәткәрләреннән һәм контракт буенча хезмәткәрләрдән тыш, I һәм II төркем инвалидлары өчен бер тапкыр бирелә торган түләүләрне киметергә һәм әлеге категориядәге гражданнар өчен 500 сум күләмендә билгеләргә.

2. Үзара салым акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1) су белән тәэмин итүнең артезиан скважинасын ремонтлау;

2) юлларны кардан чистарту.

3. Гражданнар җыенының карарын Тойма авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка чыгарырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ruhttp://www.mendeleevsk.tatar.ru/ «Енабердино авыл җирлеге» бүлегендә, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.http://pravo.tatarstan.ru.

Халык җыенында рәислек итүче,
Енабердино авыл җирлеге башлыгы Е.Н.Никифоров